КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 3 октябрь г.Казань № 786

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны, шулай ук дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны укыган чорда тәэмин итү бәясенең күләмен раслау турында

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 6 пунктының алтынчы абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2026 елның 1 гыйнварыннан, 2027 елның 1 гыйнварыннан, 2028 елның 1 гыйнварыннан план чорына гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны, шулай ук дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны укыган чорда тәэмин итү бәясенең күләмен индексацияләү коэффициентлары 1,04 күләмендә;

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны, шулай ук дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны укыган чорда тәэмин итү бәясенең күләмен кушымта нигезендә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына әлеге карарның 1 пунктының өченче абзацында каралган 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны, шулай ук дәүләт һөнәри

белем бирү оешмаларында белем алучыларны укыган чорда тәэмин итү бәясенең күләмен билгеләү белән бәйле мәсьәләләрне аңлату буенча эш алып барырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 3 октябрь, 786 нчы
карарына кушымта

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми дәүләт белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны, шулай ук дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны укыган чорда тәэмин итү бәясенең күләме

| Күрсәткеч исеме | Уку чорында бер укучыга бер көнгә күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучыларны, шулай ук уку чорында дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе | 10,7 | 11,1 | 11,5 |

---